СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» март 2023 ел № 68

**Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башлыгы, Пыжмара авыл җирлеге муниципаль хезмәткәре хезмәтенә түләү тәртибе турында» гы 2018 елның 25 декабрендәге 99 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, депутатларга, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган органнары әгъзаларына, рәисләргә, рәис урынбасарларына айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру турында" 881 нче номерлы 22.08.2022 елгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләргә, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 №182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1015 нче номерлы 17.09.2022 елгы үзгәрешләр белән, "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләменә, айлык һәм башка өстәмә түләүләргә һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибенә акчалата бүләкләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 28.04.2018 №127 карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 13.10.2022 ел №144 карары (01.11.2018 № 152, 09.10.2020 № 11, 18.01.2022 №101, 25.02.2022 №109 үзгәрешләр белән) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башлыгы, Пыжмара авыл җирлеге муниципаль хезмәткәре хезмәтенә түләү тәртибе турында» гы 99 номерлы 25.12.2018 елгы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктында «11 163» санын «16 876» белән алыштырырга;
1.2. 1 нче кушымтада «15 300» санын «17390» санына алыштырырга;
1.3. 3 нче кушымтаның 6 нчы пунктында «бер процент» сүзен «18 процент»сүзләре белән алыштырырга;
1.4. 4 нче кушымтаның 1 нче пункты карарларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1.Муниципаль хезмәткәрләрне акчалата тәэмин итү муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт вазыйфасына ярашлы рәвештә (алга таба - хезмәт хакы), сыйныф чины өчен айлык өстәмә, хезмәт хакына айлык өстәмә, муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен айлык өстәмә, айлык акчалата бүләкләү, нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр, бер тапкыр бирелә торган еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә түләүләр.»;

2.Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Җәләев